РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» апреля 2024ел г. Альметьевск № 1562

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 728 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм «Конкуренцияне яклау турында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Әлмәт шәһәр Советының 2019 елның 25 мартындагы 147 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә таянып,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 728 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 9 декабрендәге 1777 номерлы, 2022 елның 3 августындагы 1672 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

- 2.5.2 пунктындагы в) пунктчасында «(DWG форматы» сүзләреннән соң «, CSV-файл» сүзләрен өстәргә;
- 2.5.3 пунктының 3) пунктчасын төшереп калдырырга;
- 2.5.5 пунктының 2) пунктчасында «1:500 масштабында» сүзләреннән соң «(DWG форматының электрон рәвешендә, CSV-файл)» сүзләрен өстәргә;
- 2.5.6 пунктының 2 пунктчасында «1:500 масштабында» сүзләреннән соң «(DWG форматының электрон рәвешендә, CSV-файл)» сүзләрен өстәргә.;

Административ регламентка 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Административ регламентка 5 нче, 4 нче кушымталарда «ОКОНХ коды»

заказ № 1-851

сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентка 9 нчы кушымтаның 1 пунктында «өч» сүзен «биш» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И. И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Җир эшләрен башкаруга
ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Тышкы төзекләндерү элементларын бозу белән бәйле авария-торгызу эшләрен башкаруга Ордер ___

___. _____________.20__ ел

Заказчы:

_______________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүче юридик затлар өчен оешма атамасы, ИНН/, физик затлар өчен Ф.И.О)

Эшләр башкаручы:

_______________________________________________________________

(оешманың исеме, җаваплы затның Ф.И.О., телефон)

Эш төре:

_______________________________________________________________

Челтәр исемнәре

_______________________________________________________________

Эшләрне башкару адресы:

_______________________________________________________________

Инженер-коммуникация (җир) эшләрен башкаручы һәм заказчы (булган очракта) төзекләндерү объектын муниципаль ихтыяҗлар өчен файдалануга кайтару турында акт имзаланганнан соң өч ел дәвамында просадкалар һәм деформацияләр килеп чыкканнан соң биш көн эчендә үз хисабына төзекләндерүне яңадан торгызуны гарантиялиләр:

_______________________________________________________________

(эшләр төре, төзекләндерү объекты һәм аның урыны)

Җир эшләрен башкару рөхсәт ителә «___»________ 20__ елдан «___»______ 20__ елга кадәр, шул исәптән бозылган төзекләндерүне торгызу эшләрен тәгәлләү.

Эшләр башкару тәртибе һәм ысулы:
Яшел зонада эшләргә таләпләр:

Вазифаи зат (Ф.И.О.) ___________________________

(органның вазифаи заты имзасы)

Ордер билгеләнгән срок дәвамында гамәлдә.
Эшләр башкаруны ордерны тулысынча рәсмиләштергәннән соң гына башкарырга.